[Балалар үзәк китапханәсендә «Китапханәләр төне-2026» узды] // Көмеш кыңгырау. – 2026. – № 16 (30 апрель). – Б. 7.



* * *

Балалар үзәк китапханәсендә «Халыклар бердәмлеге – Россиянең көче» исеме астында «Китапханәләр төне-2026» узды. Китапханәгә кергәндә кунакларны Шүрәле белән Су Анасы каршы алды. Тамашачылар өчен «Тылсымлы дөнья» үсеш үзәге кызлары һәм малайлары чыгышы бик матур булды. Алар кечкенә артистларга кушылып җырладылар, биючеләргә алкышларын җәлләмәделәр.

Аннары кунакларны кызыклы уеннар көтә иде. Россиядә яшәүче күп төрле милләт вәкилләренең уеннары беркемне дә битараф калдырмады. Кичәнең көтеп алынган кунаклары «Җиде диңгез» камера курчак театры булды.

Кызлар һәм малайлар бик яратып мастер-класста катнаштылар, бик тырышып «Матрёшка» курчагы ясадылар. Россия картасына төрле төсләргә буяп, милли киемнәр ябыштырдылар.

Дус һәм тату булып яшәүгә ни җитә соң!

